УДК 37.01-052

ИЖ-БУБИ МӘДРӘСӘСЕ ҺӘМ МӨДӘРРИСЛӘРЕ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ КАЙБЕР ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

Р.А. Гимазова

Россия ислам институты
Казан, Россия Федерациясе
rafilyagim@gmail.com

XIX йөз ахыры – XX йөз башында Иж-Буби мәдрәсәсе кысаларында бертуган Бубилар җәдиди ысул кулланучы, җәдвәлләр нигезендә эшләүче мөселман уку йортын формалаштыра. Мәдрәсәдә дөньяви фәннәргә, чит телләрне өйрәтүгә зур игътибар бирелә. Беренче рус инкыйлабы, шәкертләр хәрәкәтенең актив чорында мәдрәсәдә шәкертләр үзидарәсе булдырып, шаукымнар булмый кала һәм «Мөхәммәдия» белән «Хөсәения»дән күчүчеләр хисабына укучылар саны да арта. Ир һәм кыз балалар мәдрәсәсендә рус теле укытуны кертү, рус класслары оештыру, земство тарафыннан әлеге сыйныфларны финансларга, рус теле укытучысын хезмәт хакы белән тәэмин итәргә мөмкинлек биргән. Мәдрәсә эшчәнлеген югары дәрәҗәгә күтәрүгә, Габдулла һәм Гобәйдулла Бубиларның киң карашлы, алдан күрүчән булулары, җәмгыятьтә барган процессларны тирән анализлый алулары ярдәм иткән. Әлеге карашлары Габдулла Бубиның «Татар мәктәпләренең истикъбале» мәкаләсендә чагылыш тапкан. Иж-Буби мәдрәсәсе татар телле имамнарны тәрбияләүгә, хөтбәләрнең татарча яңгырашына да зур өлеш керткән. Бертуган Бубилар үзләренең эшчәнлеге белән заманасы өчен алдынгы уку йортын гына гамәлгә куймыйлар, ә шул мәдрәсә кысаларында белемле, тормышта үз урыннарын тапкан, алдынгы карашлы шәкертләрне тәрбияләп, олы юлга чыгарганнар.

Ачкыч сүзләр: татар мәгарифе тарихы, Иж-Буби мәдрәсәсе, Габдулла Буби, Гобәйдулла Буби, бертуган Бубилар.

XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар тарихына мәгарифнең яңа, үзгә бер баскычка күтәрелүе белән кереп калды. Бертуган Бубилар да бу шанлы тарихта лаеклы урын алып торалар. Гобәйдулла (1866–1936), Мөхлисә (1869–1937) һәм Габдулла (1871–1922) Нигъмәтуллин-Бубилар 1895 елдан Иж-Бубый авылы мәдрәсәсен җәдиди уку-укыту ысулына күчерә башлап, 6–7 ел эчендә яңа тип уку йорты барлыкка килүенә ирешәләр. Ләкин бер

урында тукталып калмыйлар һәрвакыт эзләнү, үзгәртү эше дәвам итә. Бу процесс уку елы өчен төзелгән җәдвәлләрдән дә күренеп тора. Иске мәдрәсәләрдә укытылган дини фәннәр әкренләп дөньяви фәннәр белән алыштырыла.

Иж-Буби мәдрәсәсе үз чорының күп кенә мөселман уку йортларыннан аерылып торган. Беренче рус инкыйлабы елларында шәкертләр мәдрәсәләрдәге уку-укыту ысулларыннан, булган тәртипләрдән канәгатьсезлек күрсәтә башлагач, Иж-Буби мәдрәсәсе җитәкчеләре идарәчелекне шәкертләрнең кулларына тапшырып, күп кенә гаугалардан читтә кала алганнар. Шул чорда канәгатьсезлектән «Хөсәения»не, «Мөхәммәдия»не ташлап чыгып киткән күп кенә шәкертләр бирегә килеп үз урыннарын тапканнар.

Уку йортларының төп юнәлешен җитәкчеләр билгеләгәнлектән, уку-укыту вакытында бертуган Бубилар кулланган кайбер чараларга, ысулларга тукталырга кирәк. Бу бигрәк тә беренче рус инкыйлабы елларында үзенең уңай нәтиҗәсен күрсәтә. Башка уку йортларын ташлап чыккан шәкертләрнең күбесе Иж-Буби мәдрәсәсендә белемнәрен дәвам итә. Чөнки нәкъ шушы вакытта бертуган Бубилар уку-укыту белән җитәкчелекнең берникадәр өлешен (бу ысул үзен акламаса да) шәкертләрнең үзләренә тапшырып, күтәрелеп килүче шәкертләр хәрәкәтен берникадәр сүлпәнләндерүгә ирешәләр. Әлеге шаукым узганнан соң, җитәкчелек тулысынча яңадан мөгаллимнәр кулына күчкән. Бу алымны кулланулары, бердән, файдалы булса, икенчедән, тискәре ягы да була. Файдалы ягы шунда ки, шәкертләр канәгатьсезлек белдереп мәдрәсәне ташлап китмиләр. Чөнки, Г. Буби фикеренчә, уку-укыту ысулы белән риза булмыйча уку йортын калдырып киткән шәкертне кире парта артына утырту бик авыр. Бу шәкерт үзенә генә түгел, милләткә дә киләчәктә файда китерә алмаячак. Тискәре ягы шул – идарә итүнең йомшаруы кайбер уку-укыту әсбапларының, инвентарьнең ватылуы һәм югалуына сәбәп була.

Бу хакта да Габдулла Буби үзенең фикерен җиткезеп үтә: «Шәкертләр ни өчен мәдрәсәгә укырга киләләр?» дигән сорауга ул киләчәктә милләткә файдалы адәм булу өчен ватаннарын, ата-аналарын калдырып китәләр, ди. Ләкин бары тик гыйбадәт кылу һәм теория генә өйрәнеп, тормыш көтәр өчен бер мәгълүмат та ала алмауларына ачына. Чөнки мәдрәсәләрдә сәнгать, авыл хуҗалыгы, сату-алу хакында мәгълүмат бирмиләр. Шунлыктан яшьләй мәдрәсәдән чыгып киткән шәкертнең тормышта үз урынын табарга, эшкә урнашырга мөмкинлеге күбрәк булуын азсызыклый. Ә инде озак еллар укып та, указ ала алмаган шәкерт һәлакәткә дучар була һәм «чалмалы саилчелектән (теләнчелек. – *Р.Г.*) башка бер эшкә ярамас» ди (Бубый 1906). «Шәкертләр гыйлемнең мәгърифәттән башка булмаячагын аңладылар һәм дәрес тәртибен сорап мөдәррисләр муеннарына сарылдылар. Бу яңалыкларны кабул итәргә теләмәгән җитәкчеләр шәкертләрне куып чыгару белән куркыталар. Ә үз чиратында, куылган шәкертләр үзләре белән егермешәр шәкерт ияртеп мәдрәсәдән чыгып китәләр. Әгәр

дә ислах кылырга кирәклеген төшенмәгән мөдәррисләр аңлап мәдрәсәләрендәге тәртипне үзгәртмәсәләр, 2–3 елдан анда шәкерт калмаячагын аңласыннар» (Бубый 1906).

Бубилар, шәкертләр үзидарәсен кулланып, укучыларны уку йорты кысаларында саклап кала алганнар. Шулай итеп, XX йөз башында төрле идарә итү, уку-укыту ысулларын кулланган, аларны өйрәнеп, тәҗрибә туплаган яңа ысуллы мәдрәсә барлыкка килә.

Иж-Буби мәдрәсәсе XX йөз башында алдынгы мәдрәсәләрдән үзенең авыл җирлегендә, зур шәһәрләрдән ерак урнашуы белән дә аерылып торган. Юл мәшәкатен дә истә тотсак, әлеге уку йортына бару бик мәшәкатьле һәм чыгымлы булган. Шуңа да карамастан, ул шәһәр мәдрәсәләре белән бер дәрәҗәдә торган. Монда да бертуган Бубиларның яхшы идарәче, аналитик булулары, үз заманы уку йортларының эшчәнлеген яхшы белүе, алдан фараз кыла алулары күренә.

Габдулла Буби, шәһәр шәкертләре һәм КТУШ укучылары теориядән башка мөгамәләт белмәгәнлектән, ярминкәләрдә байларга аш ташып, кәвеш тазартып, аш-су ханәләрендә бәрәңге һәм суган әрчеп вакытларын уздыруына басым ясый. Хисап һәм мантыкый дәлилләрне белгән кешеләрне күрсәләр, чөгендер кебек кызаралар, ди. Шәкертләргә кеше белән аралашу, мөгамәләт нигезләрен мәдрәсәләрдә өйрәтергә һәм аңа зур әһәмият бирергә өнди. Бу фәннең нигезләрен белгәннәр ял вакытларында укымаган эшләренә мохтаҗ булмаячакларына басым ясый. Бу яктан авыл шәкертләренең шәһәрнекеләреннән аерылып торуын күрсәтә, чөнки җәй көне алар авылларына кайтып басуда, кыр эшләре белән мәшгуль булып, указсыз калсалар да теләнчелеккә калмыйча, иген игеп көн күрерләр, ди. Шуның өчен мәдрәсәләрдә игенчелек серләренә төшендерсәләр тагын да гүзәл булыр иде. Ләкин киресенчә, мәдрәсәләрдә «шәкертләргә сука сукалап дәресләрегезне онытып бетергәнсез диярәк зирагатьтән ваз кичмия тәшвикъ итәрләр (өндиләр. – *Р.Г.*)».

Г. Буби фикеренчә: «Мәдрәсәләрнең дә, учительский ышкулның һәр икесенең дә максаты бер – милләтне гыйлемле, бердәм итү» (Бубый 1906). КТУШны бетергәннәр аз булса да, һөнәрле булып, хисап беләнгә конторларда эшләгәннәр, ә мәдрәсә шәкертләренең русча укымаганлыкларыннан бу хезмәттән дә мәхрүм булган. Шунлыктан Г. Буби уку йортларына җәдиди фәннәр кертүне яклап чыга. Иж-Буби мәдрәсәсе шәкерте һәм мөгаллиме М. Алиев[1] үзенең истәлекләрендә атна саен уздырылган кичәләрнең тәрбия белән бергә сәяси аңны да үстерергә ярдәм итүе һәм «кайбер шәкертләр әле 1925 елда ук, Фәйзулла әфәнде (Гобәйдулла Буби) безгә тарихи материализм укыткан икән, исеме генә башка булган», дип яза (Алиев: 11–13). Габдулла һәм Гобәйдулла Бубиларның максаты: татар

[1] Мирзамөнәвир Габделханович Алиев (1888–?), 1909 елда Иж-Буби мәдрәсәсен тәмамлый, 1910 елдан шунда ук укыта башлый.

мәктәп-мәдрәсәләрендә эшләрлек тәрбияле, политехник белемле яшьләр әзерләп чыгара торган уку йорты булдыру иде, ди (Алиев: 5).

Г. Буби әле бүгенге көндә дә уку-укыту процессында кулланыла торган аңламыйча ятлатуны инкярь итә. «“Папагай кеби укып чыгар, бер нәрсә аңламас” кешедән милләткә дә, җәмгыятькә дә файдасы юк... Ислам шәригате кешеләргә гакыллары җиткәнчә һәм аңлашылырлык итеп сөйләүне хуплый. Ләкин аңламыйча уку һәм ятлау шәкертләрне наданлыкка китерә. Шәкертләр мәдрәсәләрдәге уку һәм укытуның тәртипсезлеген күреп, аны үзгәртергә кодратләреннән килмәгәнлектән укуларын ташлап качарга мәҗбүр булалар. Мөдәррисләр шәкертләрнең сөйләгән сүзен кабул итәр дәрәҗәдә зирәк булырга тиешләр. Шәкертләр, мөдәррис һәм хәлфә камчысы астында бернәрсә дә аңламаенча укып, мәдрәсәдән чыгып китәрләр. Укуга 8–10 ел сарыф итеп, 8 сәгатьлек файда да ала алмаслар. Уку йортларының, мәдрәсәләрнең төп бурычы – шәкертләргә киләчәк юлларын күрсәтү һәм һәрбер укыганын аңлатудыр» (Бубый 1906), дип азсызыклый.

Мәдрәсәнең уку программасы да замана таләпләренә туры килеп үзгәртелгән. Дөньяви фәннәр белән беррәттән, төрле чит телләрне өйрәнүгә дә игътибар ителгән: гарәп, фарсы, төрек, француз, рус телләре. Рус телен өйрәнү шәкертләргә тормыш итү өчен бигрәк тә мөһим икәнлеген аңлап, ир балалар мәдрәсәсен дә генә түгел, хәтта кыз балаларга да укытылган. Бу хакта да Габдулла Бубиның үз фикере бар: Татарлар сатучылыкка бик маһирләр, ә бу эшне алып бару өчен урыс теле бик мөһим булганлыктан, рус теле белән беррәттән хисап дәфтәрен дә өйрәтергә кирәк. «Хәтта шәкертләребез рус мәктәпләренә барудан мөстәгъни (хаҗәтсез. – *Р.Г.*) улсыннар вә мәдрәсәдән чыгу белән вазыйфа алмыя муафикъ улып, учительски ышкул шәкертләренең шәһре егерме рублә вазыйфә алуларына кызыкмасыннар» (Бубый 1906). Авторның бу фикере дә бик кызыклы. Мөселман уку йортларының башка белем бирү йортлары арасында, бүгенге көн сүзе белән әйтсәк, «конкурентоспособный» булырга тиешлеген күрсәтә. Әлеге фикердә дә бүгенге көн чаткылары күренә кебек.

Шул ук М. Алиевның истәлекләренә таянсак, 1908–1909 уку елына мәдрәсәнең һәм укытучылар коллективының бик нык әзерлегенә тукталып китә: спорт мәйданчыгы, барлык уку-укыту әсбаплары булган физика һәм химия кабинетлары булуы. Химия һәм физика дәресләренең лабораторияләрдә үтүен, география, тарих, рәсем, сызым дәресләрендә карталар сызарга өйрәтүләрен дә ассызыклый (Алиев: 7, 17).

Иж-Буби мәдрәсәсенең рус телен укытуда башлангычы земство тарафыннан да хупланылган. Ел саен земство рус класслары өчен 600 сумга кадәр акча бүлеп биргән (Гимазова 2004: 34). Татар мәктәп-мәдрәсәләре, гомумән, химаячеләр һәм ата-аналар хисабына гына тотылган. Алардан үрнәк алып, күп кенә уку йортлары земстводан акча сорап мөрәҗәгать иткәннәр. Шунлыктан, земство Иж-Буби мәдрәсәсе мөдәррисләре тара-

фыннан мөрәҗәгатьләре хупланган уку йортлары гына ярдәм ала алачак дип җавап биргән (Гимазова 2004: 34). Әлеге күренеш, мәдрәсәнең һәм аның җитәкчеләренең җәмгыятьтә уйнаган ролен күрсәтеп тора.

Габдулла Бубиның тагын бер фикеренә тукталып китәсе килә: «Мәдрәсәләрдә укылган фәннәренең күбесе фәкать имам һәм мөдәррисләргә, укытучылар мәктәбендә укылган фәннәр укытучылык итүдән башка ярамас. Шуңа күрә, теоретик фикерләр белән фәлсәфә сатып, әхлак бозуга сәбәпче булалар. Чөнки мәдрәсәне бетереп чыккан һәрбер шәкерт имам я мөдәррис, КТУШны тәмамлаганнан соң укытучы булып китми» (Бубый 1906). Шуңа күрә, бүгенге көндә дә бик актуаль фикер, «уку вакытында алынган гыйлемнәр алар һичшиксез киләчәк тормышта көн итәргә ярдәмче, юл күрсәтүче, ризык табучы булырга тиеш» (Бубый 1906). Чөнки әлеге кечкенә генә шәхси максат, тагын да биегрәгенә илтә. Габдулла Буби фикеренчә, башта кеше үз тормышына, яшәешенә кирәклекне кайгыртса, аннан соң милләтен кайгырта. Шуның өчен «бу табигый тәлапләрне күздә тотып, мәдрәсәләребездә тормышта кирәкле фәннәрне укытырга кирәк» (Бубый 1906).

Г. Буби әлеге мәкаләсендә заманы өчен актуаль һәм көн кадагында торган, чишелешен кичектерегә ярамаган мәсьәләләрне күтәреп чыккан. Кайбер күтәрелгән мәсьәләләр әле бүгенге көн күзлегеннән караганда да актуальлеген югалтмаган. Шунысын да искәртеп үтмичә ярамый: Г. Буби әлеге мәкаләдә, җәдидче буларак, яңа ысуллы мәктәпләрне яклап чыкса да, иске тип мәдрәсәләрнең һәм КТУШның эшчәнлеген бөтенләй бетереп ташламый. Һәрберсенең уңышлы, отышлы һәм тискәре якларын күрсәтеп, киләчәк мөселман уку йортларында булырга һәм максатчан шул юнәлештә эшләргә тиеш юлларны күрсәтеп үтә.

Иж-Буби мәдрәсәсенең һәм аның мөгаллимнәренең тагын бер эшчәнлекләрен искә алу кирәк. Ул да булса, хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасында шактый үзенчәлекле булган социаль-функциональ стиль – илаһият өслүбенең формалашуына керткән өлешләре.

XX йөз башына кадәр хөтбә-вәгазьләр, нигездә, гарәп телендә алып барылган. Әмма татарча уку һәм өйрәнү, фикерне үстерү, телне шома, уйны йөгерек итеп әйтә белү, ирекле әңгәмәгә, мөназарәгә (бәхәскә) хәзерләү буенча да дәресләр, гамәли шөгыльләр үткәрелгән. Җәдиди мәдрәсәләрдә шигъри кичәләрнең уздырылуы да билгеле.

XIX йөзнең ахырларында бу мәсьәләдә вәзгыять үзгәрә башлый. Ул татар халкының милләт булып формалашу, милли әдәби тел барлыкка килү, милли үзаң үсү, тәгълим-тәрбия системасында үзгәрешләр башлану белән бәйләнгән. Татарларга ислам кануннарын, дини йолаларны яшәеш өчен файдалы булырлык итеп үз ана телендә, халык сөйләм теленә якын булган аңлаешлы телдә өйрәтү, аңлату мөһим мәсьәләләрнең берсенә әверелә.

Инсаниятта тел гаять кодрәтле көчкә ия. Элеккеге заманнарда ук акыл ияләре, олуг әдипләр бу көчнең бөеклегенә, нәфислегенә сокланганнар,

аның җәмгыятьтә тоткан урынына олы бәһа биргәннәр. Тел – фани дөньяны, чынбарлыкны танып белү, аралашу-фикерләшү, инсаният тудырган матди һәм мәдәни кыйммәтләрне алдагы буыннарга тапшыру чарасы гына түгел, ул әле куәтле ышандыру һәм инандыру коралы да булып тора. Телнең тылсымлы тәэсир итү көче, барыннан да бигрәк, кешенең аңына, хистойгыларына, эчке кичерешләренә зур йогынты ясавында да чагыла. Аллаһ Тәгалә адәм балаларына бер-берсе белән аралашырга – тел, сөйләгәнне аңларга акыл биргән. Пәйгамбәребез дә ислам диненең башлангыч чорында корал урынына дәгъвәт һәм инандыру чараларыннан кулланган. Ул заманнарда ук дөрес, төгәл, ачык һәм нәфис сөйләмне барлыкка китерә торган чараларны өйрәнгәннәр, матур сөйләм сәнгатенә өйрәткәннәр, оста оратор-нотыкчылар тәрбияләүгә җитди игътибар биргәннәр.

XX йөз башында татарча хөтбә укуны башлап җибәрүчеләрнең берсе Иж-Буби мәдрәсәсенең имам-хатыйбы һәм мөдәррисе Габдулла Нигъмәтуллин-Буби була. 1906 елның 21 мартында хаҗ сәфәреннән кайтканнан соң, Габдулла Буби җомга хөтбәсен татарча укый (Гимазова 2004: 65–66). Бу – бөтенләй башка килмәслек вакыйга була. Күп төрле шау-шулар, каршылыклар, аңлашылмаучылыклар булуга карамастан, абруйлы, уй-ниятләренә инанган тәвәккәл кеше буларак, Г. Буби башлаган эш-гамәлләреннән чигенми; җомга һәм гает хөтбәләрен татар телендә укуын дәвам итә. 1908 елда «Татарча хөтбә уку дөресме?» (Бубый 1908) дигән китабын да нәшер итә. Ул анда Коръәнгә, пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) хәдисләренә, атаклы дин галимнәренең хезмәтләренә нигезләнеп, үз фикерләренең дөреслеген дәлилли. «Вәгазь, – ди ул, – җыелган халык ислам һәм милли рух белән сугарылсын, киләчәктә һәм мәңгелек яшәештә үзләренә файда китерерлек нәрсәләрне аңласыннар өчен кирәкледер. Татарларның күпчелеге гарәп телен аңламыйлар, атна саен бер үк нәрсәне сөйләүче имамнар да мәгънәсенә төшенмиләр» (Бубый 1908). Мәдрәсәдә ятлаганны, попугай кебек, атна саен бер нәрсәне кабатлаучы имамнарның халыкка бернинди дә файдасы юклыгына басым ясый. «Әгәр кешеләр нәрсә турында сүз баруын аңламыйлар икән, моны хөтбә дип исәпләргә мөмкинме?» – ди. Габдулла Буби җомга һәм гает намазларында татарча хөтбә укуны нәзари яктан да дәлилләп бирә. Әлеге карашта торган мөгаллим, үзенең шәкертләренә дә, татар телендә хөтбә укуның мөһимлеген, аның җәмгыять өчен кирәклеген төшендергән.

Элек-электән үк татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дә, исламият кануннарын ныклап үзләштерү белән берлектә, сүз сәнгатенә, сөйләшү әдәбенә дә өйрәткәннәр, ораторлык сәнгатен үзләштергән һәм Аллаһ Тәгаләнең сүзен, Мөхәммәд (сгв) хәдисләрен адәм балаларына аңлаешлы, оста җиткерә белүче имам-хатыйблар хәзерләүгә зур урын бирелгән. Шунлыктан дини уку йортларында төп фәннәр булган Коръән, тәҗвид, Коръән тәфсире, гакаид, фикъһ, ислам һәм пәйгамбәрләр тарихы, шәригать гыйлемнәре, гарәп телен өйрәтү белән беррәттән, әхлак, риторика, фәлсәфә, мантыйк кебек фәннәр дә укытылган. Сөйләшә-

аралаша белү, сүз сәнгатенә ия булу иң мәртәбәле һәм иң кирәкле гамәлләрнең берсе итеп саналган.

Иж-Буби мәдрәсәсе укытучылары һәм шәкертләре татарлар арасында ислам дине тәгълиматын татарча вәгазьләүгә зур өлеш кертә. Исламны киң халык массаларына аңлаешлы булган татар телендә аңлатуны, шулай иткәндә, кеше күңеленә әйбәтрәк йогынты ясау мөмкинлеген күрсәтәләр. Бер үк вакытта Г. Бубиның хатыйблык осталыгы турында да әйтеп узасы килә. Мәдрәсәдә үзгәртеп-кору чорында чыккан төрле авырлыкларны да, аңлату, дәлилләү ысулы белән тирә-як халыкны, муллаларны үз ягына аудара алган. Моның өчен бертуган Бубиларга динне, Коръәнне белү генә түгел, ана телен камил белү, аның сөйләм байлыкларыннан оста файдалану, ораторчылык сәләте дә ярдәм иткән. Заманында Иж-Буби мәдрәсәсен тәмамлаган һәм шунда татар теле мөгаллиме булган Җамал Вәлиди дә үзенең остазы турында: «Җанлы, үткен, ялкынлы кеше иде. Адымнарын икеләнүсез атлый, фикерләрен ачык, кискен йөртә», – дип язган (Вәлиди 1999: 166).

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, бертуган Бубилар үзләренең эшчәнлеге белән заманы өчен алдынгы уку йортын гына гамәлгә куймыйлар, ә шул мәдрәсә кысаларында белемле, тормышта үз урыннарын тапкан, алдынгы карашлы шәкертләр тәрбияләп, олы юлга чыгарганнар. Совет власте урнашканнан соң, ТАССР совнаркомы һәм җирле органнарда җитәкче урыннарда Иж-Буби мәдрәсе шәкертләрен күпләп күрү моңа мисал булып тора (Гимазова 2004: 184–219).

ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

Алиев М. Истәлекләр // Отдел рукописей и редких книг КФУ. Т 3258.

Бубый Г. Татар мәктәпләренең истикъбале // Казан мөхбире. 1906. № 77.

Бубый Г. Татарча хөтбә уку дөрестме? Казан: Үрнәк, 1908.

ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Вәлиди Ж. Габдулла Бубый // Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: тарихи-документаль җыентык. Казан: Рухият, 1999.

Гимазова Р. Просветительская деятельность Нигматуллиных-Буби (конец XIX – начало XX вв.). Казань: Печатный Двор, 2004.

Автор турында белешмә: Гимазова Рафилә Алмарисовна – тарих фәннәре кандидаты, Татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы җитәкчесе, Россия ислам институты (420049, Газовая ур., 19, Казан, Россия Федерациясе); rafilyagim@gmail.com

Редакциягә керде 17.03.2022 *Кабул ителде 22.04.2022*

НЕКОТОРЫЕ НАПРАВЛЕНИЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ МЕДРЕСЕ ИЖ-БУБИ И ЕГО МУДАРРИСОВ

Р.А. Гимазова

Российский исламский институт
Казань, Российская Федерация
rafilyagim@gmail.com

В конце XIX – начале XX вв. братья Буби реорганизовали работу медресе Иж-Буби, создав мусульманское учебное заведение, работающее на основе джадидского метода. Особое внимание в нем уделялось светским наукам, изучению иностранных языков. В период активного движения шакирдов во время Первой русской революции в медресе создается шакирдское самоуправление, способствовавшее предотвращению расколов. В это же время растет число студентов Иж-Буби в результате перехода некоторого числа учащихся из медресе «Мухаммадия» и «Хусаиния». Введение русского языка в мужском и женском медресе, организация русских классов открыли возможность получения земского финансирования этих классов, что покрывало расходы на оплату труда учителей русского языка. Широкий кругозор, дальновидность братьев Габдуллы и Губайдуллы Буби, умение глубоко анализировать происходящие в обществе процессы – все это повышало образовательный уровень медресе. Эти взгляды нашли отражение в статье Габдуллы Буби «Татар мәктәпләренең истикъбале» («Будущее татарских школ»). Медресе Иж-Буби внесло большой вклад в воспитание татароязычных имамов, в звучание проповедей на татарском языке. Своей деятельностью братья Буби не только учредили передовое учебное заведение, но и в рамках этого медресе воспитали и подготовили высокообразованных учеников, которые благодаря своим прогрессивным взглядам смогли занять достойное место в общественном пространстве того времени.

Ключевые слова: история татарского образования, медресе Иж-Буби, Габдулла Буби, Губайдулла Буби.

Для цитирования: Гимазова Р.А. Иж-Буби мәдрәсәсе һәм мөдәррисләре эшчәнлегенең кайбер юнәлешләре // Историческая этнология. 2022. Т. 7, № 1. С. 14–23. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-1.14-23

Сведения об авторе: Гимазова Рафиля Алмарисовна – кандидат исторических наук, заведующая кафедрой татарского языка и национальной культуры Российского исламского института (ул. Газовая, 19, Казань, Российская Федерация); rafilyagim@gmail.com

Поступила 17.03.2022 *Принята к публикации 22.04.2022*

CERTAIN ASPECTS OF THE WORK OF IZH-BUBI MADRASAH AND ITS MUDARISSES

R.A. Gimazova
Russian Islamic Institute
Kazan, Russian Federation
rafilyagim@gmail.com

At the end of XIX – beginning of XX centuries the Bubi brothers established the Muslim educational institution, which operated after the Jadid method, as part of Izh-Bubi madrasah. Much attention there was paid to secular sciences and the study of foreign languages.

During the First Russian Revolution, when the shakirds were active, the madrasah became known for the establishment of shakird self-government. This helped to prevent ideological splits and to increase the number of students due to the transfer of students from Muhammadiyah and Khusainia.

Later, Russian language lessons were included in the male and female madrases, and lessons for Russian-speakers were introduced. As a result of these changes, the zemstvo paid for the language classes and the Russian language teachers could get salaries.

The madrasah further developed thanks to the broad-based knowledge, forward-thinking approach of Gabdulla and Gubaidulla Bubi, as well as their ability to deeply analyze the processes that took place in society during that period.

These ideas are reflected in Gabdulla Bubi's article *"Tatar maktaplerenen istikbale"* ("The future of Tatar schools").

Izh-Bubi madrasah had a great impact on the education of Tatar-speaking imams and the Tatar version of sermons.

The Bubin brothers not only established an advanced educational institution but also educated and guided their students to a worthful path in life and progressive views.

Keywords: History of Tatar education, Izh-Bubi madrasah, Gabdulla Bubi, Gubaidulla Bubi.

For citation: Gimazova R.A. Izh-Bubi mädräsäse häm mödärrisläre eshchänlegeneñ kayber yunäleshläre [Certain aspects of the work of Izh-Bubi madrasah and its mudarisses]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2022, vol. 7, no. 1, pp. 14–23. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-1.14-23 (In Tatar)

REFERENCES

Walidy J. Gabdulla Bubyy [Bubi G.]. *Bertugan Bubyylar həm Izh-Bubyy mädräsäse: tarikhi: dokumental' jyyentyk* [The Bubi Brothers and Izh-Bubi madrasah: The collection of history and records]. Kazan: Ruhiyat Publ., 1999. (In Tatar)

Gimazova R. *Prosvetitel'skaya deyatel'nost' Nigmatullinykh-Bubi (konets XIX – nachalo XX vv.)* [The Educational Activity of the Nigmatullins-Bubi (the late 19th – beginning of 20th centuries)]. Kazan: Print Center, 2004. (In Russian)

About the author: Rafilya A. Gimazova, Cand. Sc. (History), Head of the Department of Tatar Language and National Culture, Russian Islamic Institute (19 Gazovaya St., Kazan 420049, Russian Federation). rafilyagim@gmail.com

Received March 17, 2022 *Accepted for publication April 22, 2022*